ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово, 422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МАКЫЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 110 нче йорт, Макыл авылы, 422582

Тел.: (84379) 34-4-74, факс: (84379) 34-4-95.

15.04.2024 № 01

На №____________от____________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең  Сеитово авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2024 елның 08 ноябреннән 01 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы? - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сеитово авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау) дигән сорау буенча 2024 елның 13 апрелендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә халык җыенында катнашучы 80 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 42 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе»  позициясе өчен - гражданнар җыенының 42 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен тавыш бирде - җыенның 0 катнашучысы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 08.11.2023 ел  № 01 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә сез ризамы?- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сеитово авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау)» дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында халык җыены нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: П.Е. Карпухин